Муниципаль бюджет гомумбелем бирү учреждениясе "Татарстан Республикасы Нурлат шәһәре 8нче номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе"

| « Каралды » методик берләшмә утырышында Методик берләшмә җитәкчесе ___________ /Мазитова Л.К./ Протокол № 1 « 27 » август 2018 ел | «Килешенде » Укыту эшләре буенча директор урынбасары________ /Григорьева Г.Д./ « 28 » август 2018 ел | « Раслыйм» Мәктәп директоры ________ / Граф А.А./ Приказ № 253 « 29 » август 2018ел |
|---|---|---|

# 1 нче квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы Хатыйпова Фәридә Җамалетдин кызының рус мәктәбенең (1-4) сыйныфта укучы татар балаларына туган тел ( татар теле ) дәресеннән эш программасы

***база дәрәҗәсе***

**"29" август 2018 нче ел**
**№1 беркетмә белән педагогик**
**киңәшмә утырышында кабул ителде.**

**2018-2019 нчы уку елы**

**Укытуның көтелгән нәтиҗәләре**

**Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр:**

- шәхеснең әхлакый-рухи сыйфатларын камилләштерү:
- милли горурлык, гражданлык хисләре формалаштыру;
- әхлак нормаларын, җәмгыятьтә яшәү кагыйдәләрен үзләштерү;
- күршеңә ярдәм итүдә танып-белү инициативасы күрсәтү;
- үз алдыңа максат кую, аңа ирешү юлларын эзләү;
- уңышларыңа яки уңышсызлыкларыңа, аларның сәбәпләренә дөрес бәя бирү;
- индивидуаль эшчәнлек стилен формалаштыру:
- төрле мәгълүмат чараларын (сүзлекләр, Интернет ресурслар һ.б.) танып-белү һәм аралашу вакытында куллану;
- актив, мөстәкыйль, иҗади фикер йөртүче, фәнни-тикшеренү эшчәнлеген башкара алырлык шәхес буларак формалашуны дәвам итү;
- үзең алган белем күнекмәләрен тормышның төрле шартларында куллана белергә өйрәнү.

**Метапредмет нәтиҗәләр**

Танып-белү гамәлләре:
- танып-белү юнәлешендәге максатларны билгеләү;
- укучының үз эшчәнлеген мөстәкыйль рәвештә оештыра
- белүе, бәяләве, үзенең кызыксынучанлык өлкәсен билгеләве;
- мөстәкыйль рәвештә теманы, куелган проблеманы ача белү, фикер йөртү;
- уку мәсьәләсе тирәсендә логик фикерләү;
- фикерләүдә логик чылбыр төзү;
- тема тирәсендәге төп билгеләрне аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштыру;
- төрле мәгълүмат чаралары белән эшли, кирәкле мәгълүматны таба, анализлый һәм үз эшчәнлегендә куллана белү;
- фонетик анализ ясау күнекмәләре булдыру;
- сүз ясалыш ысулларыннан файдаланып сүзләр ясый белү , сөйләм эшчәнлегендә алардан дөрес һәм урынлы файдалана белү;
- телне әдәбият, рәсем һәм музыка сәнгате белән бәйләп, сүз сәнгатенең кыйммәтен күрсәтү, матурлыкны танырга өйрәтү;
- тел берәмлекләренең әдәби әсәр тудырудагы ролен билгеләү;
- татарчадан русчага, русчадан татарчага тәрҗемә итү юлы аша фразеологик берәмлекләрнең эчтәлегендәге фәлсәфәне үзләштерү.

Коммуникатив УУГ
- тыңлый белү;
- диалог төзүдә һәм коллектив фикер алышуда катнашу;
- сыйныфташлары һәм укытучы белән уку эшчәнлеген оештыруда хезмәттәшлек итү;
- төрле фикерләрне исәпкә алып эш итү;
- үз фикерен дәлилли белү, тормыштан мисаллар китерү;
- төрле җавапларны тыңлау, чагыштыру, нәтиҗә ясау;
- үз фикерен тулы һәм төгәл итеп әйтә белү;

- күмәк эш вакытында уртак фикергә килү;
- мәгълүмат туплауда үзара хезмәттәшлек итүдә инициативасы күрсәтү;
- укылган текстлар буенча сораулар бирә алу;
- бирелгән текстларның дәвамын үзлектән сөйләп карау,фикер әйтү автор фикере белән чагыштыру;
- үз эшен контрольдә тоту, сыйныфташларына ярдәм итү;
- коммуникатив күнекмәләрнең кеше тормышындагы ролен билгеләү;
- үз фикерләрен телдән һәм язмача җиткерә белү;
- башкаларны тыңлый, киңәш бирә белү;
- сыйныфташлары каршында төрле темаларга, башкарылган проектлар буенча чыгыш ясау;
- иптәшенең гамәлләрен бәяләү, күрше белән хезмәттәшлек итү.

Регулятив УУГ:
- дәреснең проблемасын (тема) һәм максатларын мөстәкыйль формалаштыру;
- проблеманы аңлап гипотеза чыгару, үз фикереңне дәлилләр китереп раслый белү, телдән (диалогик, монологик) һәм язма сөйләмдә сәбәп-нәтиҗә бәйләнешен аерып алу, нәтиҗәләрне формалаштыру;
- максатка ирешү юлларын билгеләү;
- үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәле булуына ирешү, үз эшчәнлегеңне контрольгә алу;
- укытучы белән бергәләп, үз эшен, иптәшләренең җавапларын бәяләү;
- кагыйдә, күрсәтмәләрне истә тоту һәм аларга ияреп гамәлләр кылу;
- эшләнгән эшкә бәя бирү, сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү.

**Предмет нәтиҗәләр:**
- фонетик, сүз төзелеше һәм лексик берәмлекләр белән эш итүне ныгыту;
- исем, орфоэпик һәм орфографик кагыйдәрне үзләштерү, гамәли куллана белү;
- сүзнең лексик мәгънәсен билгели һәм сөйләмдә урынлы куллана белү;
- тел материалы белән логик фикерләүне сорый торган эш төрләрен башкару;
- телнең сүзлек составын куллану өлкәсе, активлыгыннан чыгып урынлы файдалану;
- сүзләрнең төзелешен һәм ясалышын тикшерү;
- бирелгән темаларга, тормыштан алган фикер-карашларга, хис-кичерешләргә ни-гезләнеп, кечкенә хикәяләр язу;
- укучыларны иҗади эшчәнлеккә тарту, проект эшләре белән кызыксындыру.

## Программа материалының эчтәлеге.

**I сыйныф (68 сәг)**

**1.Әзерлек чоры (4 сәг)**

а) Безнең  мәктәп (1 сәгать).
Исәнләшү, танышу, саубуллашу. Мәктәп, сыйныф укучылары һәм укытучы турында сөйләшү. Саннарны актив кулланылышка кертү.
Нишли?соравына җавап биреп, предметның (затның) эше турында хәбәр бирү. Нинди? соравына җавап биреп, әйбернең билгесен белдерү.
Кайда? кая? сорауларына җавап биреп, эшнең үтәлү урыны турында хәбәр итү.
Лексика. Малай, кыз, исемем, утырыгыз, мин, син, ул, минем, синең, аның, миңа, сиңа, аңа; исәнмесез, исәнме, сәлам, сау булыгыз, рәхмәт; мәктәп, сыйныф, укытучы, китапханәче, акбур, такта, каләм, дәфтәр, китап, сыйныф җитәкчесе, кыңгырау, тәнәфес, ашханә; кечкенә, зур; бер, ике, өч, дүрт, биш.
б).  Язу элементлары(1 сәг)
Язу юллары,язу элементлары белән таныштыру.Язу элементлары,таякчыклар,дулкынлы сызыклар,ярымтүгәрәкләр,предмет рәсемнәрен ясый белү. Ыргаклы авыш сызыклар сызу.Астан өскә элмәкле сызыклар сызу
в)  Хәреф элементлары  (2 сәгать).
Хәреф элеметларын язу.Язу юлларын билгеләү.юл һәм баш хәреф элементларын язу.Юл һәм баш хәрефләрне коллеграфик дөрес язу

**2.Әлифба чоры (64 сәг)**

Авазлар һәм хәрефләр (58 сәг.)
Аваз һәм хәреф. Сузык һәм тартык авазлар. Калын һәм нечкә сузыклар һәм аларның хәрефләре. Э, о, ө, е, ю, я хәрефләрен сүздә дөрес язу кагыйдәләре. Иҗекләр. Сүзләрне иҗекләргә бүлү. Сүзләрне юлдан юлга күчерү.
Тартык аваз хәрефләре. Й, в, т, г, м, н, ң хәрефләрен сүздә дөрес язу кагыйдәләре.
Алфавит. Алфавитны белүнең әһәмияте.
Сүз (2сәг.)
Предмет, билге, хәрәкәт һәм сүз. Авазлар һәм сүз.
Морфология (2сәг.)
Кем? нәрсә? сорауларына җавап булган сүзләр.
Нишли? нишләде? сорауларына җавап булган сүзләр.
Нинди?кайсы? сорауларына җавап булган сүзләр.
Синтаксис (2 сәг.)

Җөмлә. Җөмлә нәрсәне белдерә. Җөмлә нәрсәләрдән тора. Җөмләдә сүзләр бәйләнеше. Сөйләм төзү.

**II сыйныф ( 70 сәгать)**

Кабатлау ( 5 сәг.)

Сүзләрне иҗекләргә бүлү һәм юлдан юлга күчерү. Аерым сүзләр һәм сүзтезмәләрне, җөмләләрне дөрес итеп уку һәм язу. Кем? нәрсә? нинди? кайсы? нишли? сорауларына җавап бирә торган сүзләрне табып әйтү, алар белән җөмләләр төзү. Баш хәрефтән языла торган сүзләрне кабатлау.

Авазлар һәм хәрефләр (17 сәг.)

Татар теленең алфавиты һәм аны өйрәнү. Сүзләрне алфавит тәртибендә язу. Тартык һәм сузык авазлар. Яңгырау һәм саңгырау тартыклар. Я, ю, е хәрефләре, алар кергән сүзләне дөрес уку һәм язу. Татар теленең үзенчәлекле тартыклары [ ж ], [һ ], [ң ] авазлары кергән сүзләрне дөрес язу. Ц, щ хәрефләре кергән сүзләрне дөрес уку һәм язу. Ъ һәм ь хәрефләре кергән схзләрне дөрес уку һәм язу. Сүзлек диктантлары язу.

Сүз (11сәг.)

Иҗек. Сүзләрне иҗекләргә бүлү. Татар телендә сүз басымы. Кабатлау. Диктант язу.

Морфология (19сәг.)

Исем, аның мәгънәсе, сораулары. Берлек һәм күплек сан формалары, күплек сан кушымчаларының дөрес язылышы.

Фигыль, аның мәгънәсе, сораулары. Фигыльләрнең заман формалары турында төшенчә бирү.

Сыйфатның мәгънәсе, сораулары. Сыйфатның төс, тәм, форма, күләм, холык һәм башка билгеләрне белдерүе. Сыйфатларны шуңа карап төркемнәү. Сыйфатның җөмләдә исемгә бәйләнеп килүе. Сөйләмдәге әһәмияте, антоним сыйфатларны сөйләмдә куллану. Кабатлау. Диктант язу.

Синтаксис (10сәг.)

Җөмлә. Җөмләнең баш кисәкләре. Ия һәм хәбәр.

Кабатлау(8 сәг)

Укытучының сорауларын аңлап, аларга гади җөмләләр белән җавап бирү. Бирелгән тама буенча 4-6 җөмлә төзеп әйтү, бирелгән диалогны ( монологны) дәвам итү. Диктантлар язу. Аерым рәсемнәрне сурәтләп биргәндә, исем, сыйфат, фигыльләрне дөрес куллану.

**III сыйныф ( 70 сәгать)**

Кабатлау (5 сәг.)
Авазлар һәм хәрефләр. Сузык һәм тартык авазлар.
Ъ һәм ь билгеләре. Җөмләнең баш кисәкләре. Исем, сыйфат, фигыльләрне кабатлау. Сүзләргә фонетик анализ ясау.
Сүз (10 сәг.)
Сүзләрнең туры һәм күчерелмә мәгънәләре. Бер мәгънәле һәм күп мәгънәле сүзләр. Синоним, антоним, омоним сүзләр. Аларны текстан табу, сөйләмдә дөрес һәм урынлы куллана белү. Сүзлекләр турында мәгълүмат бирү һәм алар белән эшләргә өйрәтү. Сүзлек диктанты язу.
Сүз төзелеше һәм ясалышы (10 сәг.)
Тамыр һәм кушымча. Тамырдаш сүзләр. Кушымчалар һәм аларның төрләре. Тамыр, ясалма, парлы, кушма сүзләр. Кабатлау. Диктант язу.
Морфология (27 сәг.)
Исем турында өйрәнгәннәрне искә төшерү. Уртаклык һәм ялгызлык исемнәр. Исемнәрнең килеш белән төрләнүе. Берлек һәм күплек сандагы исемнәрнең килеш белән төрләнеше. Кабатлау (тест). Диктант язу.
Алмашлыклар. Зат алмашлыклары. Сорау алмашлыклары. Алмашлыкларның килеш белән төрләнеше.
Фигыль. Фигыльләрне сөйләмдә дөрес куллану. Фигыльләрнең заман һәм зат- сан белән төрләнүе. Аларның барлык һәм юклык формалары. Кабатлау (тест).
Сыйфат. Сыйфатлар турында белгәннәрне искә төшерү. Синоним, антоним сыйфатлар. Сыйфатларның исемне ачыклап килүе. Аларның җөмләдәге роле.
Сан. Аның мәгънәсе, сораулары. Аларны сөйләмдә дөрес куллану. Татар телендә сан белән саналмышның бәйләнеш үзенчәлекләре.
Синтаксис (11 сәг.)
Өйрәнелгән сүз төркемнәрен кулланып, сүзтезмә һәм җөмләләр төзү, аларны сөйләмдә дөрес куллану. Җөмләнең коммуникатив төрләре: хикәя, сорау, өндәү, раслау, инкарь җөмләләр. Түгел кисәкчәсен, юк хәбәрлек сүзләрен куллану.
Җөмләнең баш кисәкләрен билгели белү.
Аергыч турында мәгълүмат бирү. Аларны сөйләмдә дөрес куллану. Русча җөмләләрне татарчага тәрҗемә итү. Татар телендә җөмләдә сүз тәртибе ( ия белән хәбәрнең , аергыч белән аерылмышның урыннары
Кабатлау (8сәг.)

6-8 җөмләдән торган диалоглар төзи белү. Укыган яки тыңлаган өзекнең эчтәлеген тулы җөмләләр белән белдерү. Башлаган диалогны яки монологны дәвам итү. Күчереп язу күнегүләре.
Сүз төркемнәрен кабатлау.Җөмләнең баш кисәкләрен ,җөмләнең иярчен кисәкләрен кабатла

**IV сыйныф (70 сәг)**

1.Үткәннәрне кабатлау (5 сәг.)

I-III нче сыйныфларда авазлар һәм хәрефләр турында үткәннәрне кабатлау: сузык һәм тартык авазлар, ъ һәм ь хәрефләре, сүзлекләрләруны дәвам итү, татар һәм рус телләрендә тамыр һәм кушымчаларның үзенчәлекләрен искә төшерү, өйрәнгәннәрне ныгыту. Морфология һәм синтаксис буенча үткәннәрне кабатлау.

5 сәг.

II Морфология (39сәг)

Исем. Яңгырау һәм саңгырау, борын авзларына беткән исемнәрнең килеш белән төрләнеше.

Исемнәрнең тартым белән төрләнеше, берлек һәм күплек сан формалары.

Сыйфатның дәрәҗә формалары, аларның дөрес язылышы.

Сан. Предметның төгәл микъдарын, саналу тәртибен белдерә торган саннар. Аларныә сөйләмдәге әһәмияте. Татар телендә саналмышның куллану Үзенчәлекләре.Тәртип саннары белән танышу.

Алмашлыклар. Тартым алмашлыклары, зат алмашлыклары, күрсәтү алмашлыклары. Аларның мәгънәләре. Тартым алмашлыкларын сөйләмдә дәрес куллану.

Фигыль. Боерык фигыльләр. Аларның зат- сан белән төрләнеше. Боерык фигыльләрне сөйләмдә тиешле интонация белән әйтү.

Үткән һәм киләчәк заман хикәя фигыльләр. Аларның зат- сан белән төрләнеше.

Бәйлек һәм бәйлек сүзләр. Аларны сөйләмдә дөрес куллану.

Үткәннәрне ныгыту (тест)

III Синтаксис (17 сәг)

Татар һәм рус телләрендә сүзтезмә һәм җөмлә, аларда сүзләрнең урнашу тәртибе.

Җөмләнең баш кисәкләре. Җыйнак һәм җәенке җөмләләр. Җөмләнең иярчен кисәкләре. Җөмләдә аергычның тәртип саны белән белдерелүе.

Җөмләнең тиңдәш кисәкләре, алар янында җыючы һәм каршы куючы теркәгечләр. Алар янында тыныш билгеләре.

Эндәш сүзләр. Алар янында тыныш билгеләрен дөрес кую.

Кабатлау. Диктантлар язу. Контроль күчереп язу. Карточкалар белән эшләү

IV Кабатлау (9сәг)

Өйрәнелгән сүз төркемнәренең тиешле формаларын кулланып, хикәя төзеп яза белү. Укылган өзек буенча план төзеп, хикәя төзеп яза белү..

Сүз төркемнәрен кабатлау.Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләрен кабатлау.Үткәннәрне гомумиләштереп кабатлау.

**I сыйныф туган тел (татар теле) дәресеннән календарь – тематик план.**

**( Атнага 2 сәгать исәбеннән елга 68 сәгать)**

| №п/п | Бүлек № | Тема | Дәрес саны | Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | план | факт |
| **1. Әзерлек чоры (4 сәг)** | | | | | |
| 1. | 1.1 | БСҮ “Исәнме,мәктәп”<br>Танышу дәресе | 1 | 3.06 | |
| 2. | 1.2 | Хәреф элементлары,<br>ыргаклы кыска,астан өстән<br>ыргаклы авыш сызыкларязу | 1 | 6.09 | |
| 3. | 1.3 | Язу элементлры<br>ярымтүгәрәкләр,<br>дулкынлы сызыклар,хәреф элементларын язу | 1 | 10.09 | |
| 4. | 1.4 | Хәреф элементлары<br>Астан ,өстән элмәкле сызыклар | 1 | 13.09 | |

2 нче сыйныфта укучы татар балалары туган тел (татар теле) дәресеннән календарь тематик план.

**(70 сәг)**

| Б | Дәрес темасы | С с | Ү тк әрүв акы ты | п |
| --- | --- | --- | --- | --- |
| | **1 1 нче сыйныфта үткәннәрне кабатлау (5 сәг)** | | | |
| 1 | Исәнме, мәктәп! Авазлар һәм хәрефләр. | 1 | 5 | |
| 1 | Сузык һәм тартык авазлар. | 1 | 7 | |
| 1 | Ижек. Сүзләрне юлдан-юлга күчерү. | 1 | 1 | |

1

| | | | | | |
| --- | --- | --- | --- | --- | --- |
| 13 | 2.8 | Ике аваз белдерүче я,ю,е хәрефләре | 1 | 17.10 | |

| | | | | |
| --- | --- | --- | --- | --- |
| | Тартык аваз һәм аның хәрефләре | 1 | 19.10 | |
| | БСҮ. Рәсем буенча хикәя төзеп язу “Күзге эшләр”. | 1 | 24.10 | |
| | Авазлар һәм хәрефләр темасын өйрәнүгә контроль диктант№1 “Бакчада” | 1 | 26.10 | |
| | Яңгырау һәм саңгырау тартыклар | 1 | 7.11 | |
| | Хаталар өстендә эшләү [х ], [һ ] авазлары х,һ хәрефләре. | 1 | 9.11 | |
| | [к] [къ] [гъ] [г] к,г хәрефләре | 1 | 14.11 | |
| | [ч] [ң] авазы,ч,ң хәрефләре | 1 | 16.11 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 21 | 2.16 | Ь,һәм ъ хәрефләре | 1 | 21.11 | |
| 22 | 2.17 | Тартык һәм сузык аваларга фонетик анализ | 1 | 23.11 | |
| **3. Сүз (11 сәг)** | | | | | |
| 23 | 3.1 | БСҮ “Сүз турында төшенчә” | 1 | | |
| 24 | 3.2 | Тамыр сүзләр турында төшенчә | 1 | 28.11 | |
| 25 | 3.3 | Тамыр һәм кушымча | 1 | 30.11 | |
| 26 | 3.4 | Сүз ясагыч кушымчалар | 1 | 5.12 | |
| 27 | 3.5 | Сүзләрдән җөмләләр төзү | 1 | 7.12 | |
| 28 | 3.6 | Ясалма сүзләр турында төшенчә | 1 | 12.12 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 29 | 3.7 | Тамырдаш сүзләр турында төшенчә | 1 | 14.12 | |
| 30 | 3.8 | Тамырдаш сүзләр турында төшенчә | 1 | 19.12 | |
| 31 | 3.9 | Сүз бүлеген кабатлау | 1 | 21.12 | |
| 32 | 3.10 | Сүз бүлеген кабатлауга контроль диктант№2 «Кышкы уеннар» | 1 | 26.12 | |
| 33 | 3.11 | Хаталар өстендә эш БСҮ“Кышкы уеннар” | 1 | 16.01 | |
| | | | | | |
| **4. Морфология (19 сәг)** | | | | | |
| 34 | 4.1 | Сүз төркемнәре.Исем | 1 | 18.01 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 35 | 4.2 | Татар һәм рус телендә исемнәргә сорау кую үзенчәлекләре Сүзлек диктанты | 1 | 23.01 | |
| 36 | 4.3 | Берлек һәм күплек сандагы исемнәр | 1 | 25.01 | |
| 37 | 4.4 | Ялгызлык исемнәр турында төшенчә | 1 | 30.01 | |
| 38 | 4.5 | Уртаклык исемнәр турында төшенчә | 1 | 1.02 | |
| 39 | 4.6 | Бсү “Безнең мәктәп” | 1 | 6.02 | |
| 40 | 4.7 | Фигыль турында төшенчә | 1 | 8.02 | |
| 41 | 4.8 | БСҮ. “Ял көне”, хикәя төзү. | 1 | 13.02 | |
| 42 | 4.9 | Берничә предметның эшен белдергән сүзләр | 1 | 15.02 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 43 | 4.10 | БСҮ”Минем яраткан әнием” | 1 | 20.02 | |
| 44 | 4.11 | Хәзерге заман хикәя фигыль | 1 | 22.02 | |
| 45 | 4.12 | Хәзерге заман хикәя фигыль | 1 | 27.02 | |
| 46 | 4.13 | Үткән заман хикәя фигыль | 1 | 1.03 | |
| 47 | 4.14 | Киләчәк заман хикәя фигыль | 1 | 6.03 | |
| 48 | 4.15 | Сыйфат сүз төркеме | 1 | 8.03 | |
| 49 | 4.16 | Предметның төрле билгесен белдерүче сыйфатлар | 1 | 13.03 | |
| 50 | 4.17 | Сыйфат сүз төркемен өйрәнүне ныгыту | 1 | 15.03 | |
| 51 | 4.18 | Сүз төркемнәрен кабатлау | 1 | 20.03 | |
| 52 | 4.19 | Сүз төркемнәре буенча контроль диктант №3 “Башкала” | 1 | 22.03 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| **5.Синтаксис (10сәг)** | | | | | |
| 53 | 5.1 | Хаталарөстендә эш.Сүзтезмәләрдән җөмләләргә | 1 | 3.04 | |
| 54 | 5.2 | Сүзтезмәләрдән җөмләләргә | 1 | 5.04 | |
| 55 | 5.3 | БСҮ “Яз килә,яз көлә” | 1 | 10.04 | |
| 56 | 5.4 | Сүзләрдән җөмләләргә | 1 | 12.04 | |
| 57 | 5.5 | Сүзләрдән җөмләләргә | 1 | 17.04 | |
| 58 | 5.6 | Җөмләнең баш кисәкләре | 1 | 19.04 | |
| 59 | 5.7 | Җөмләнең баш кисәкләре | 1 | 24.04 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 60 | 5.8 | Татар һәм рус телендә ия белән хәбәрнең җөмләдә урнашу тәртибе | 1 | 26.04 | |
| 61 | 5.9 | БСҮ Тәрҗемә итү күнегүләре | 1 | 3.05 | |
| 62 | 5.10 | Җөмләнең баш кисәкләрен кабатлау | 1 | 8.05 | |
| **6. Кабатлау ( 8 сәг)** | | | | | |
| 63 | 6.1 | Сүз төркемнәрен кабатлау | 1 | 10.05 | |
| 64 | 6.2 | Җөмләнең баш кисәкләрен кабатлау | 1 | 15.05 | |
| 65 | 6.3 | БСҮ. “Туган шәһәрем”. Диалог төзү. | 1 | 17.05 | |
| 66 | 6.4 | Үткәннәрне гомумиләштереп кабатлау | 1 | 22.05 | |
| 67 | 6.5 | Грамматик биремле күчереп язу | 1 | 24.05 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 68 | 6.6 | Еллык арадаш аттестация эше Контроль диктант «Урманда» | 1 | 27.05 | |
| 69 | 6.7 | Хаталар өстендә эш.Җөмләнең баш кисәкләрен кабатлау | 1 | 29.05 | |
| 70 | 6.8 | Йомгаклау дәресе | 1 | 30.05 | |

3 нче сыйныф  татар төркемнәре өчен туган тел(татар теленнән) календарь тематик план

| №п/п | Бүлек № | Дәрес темасы | Сәг саны | Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | План | факт |
| **1 2 НЧЕ СЫЙНЫФТА ҮТКӘННӘРНЕ КАБАТЛАУ(5 сәг)** | | | | | |
| *1* | 1.1 | **БСҮ “Туган телем-иркә гөлем”** | **1** | 3.09 | |
| *2* | 1.2 | Авазлар һәм хәрефләр.Сузык һәм тартык авазлар | 1 | 8.09 | |
| *3* | 1.3 | Сүзләргә фонетик анализ | 1 | 10.09 | |
| *4* | 1.4 | Сүз төркемнәрен кабатлау | 1 | 15.09 | |
| *5* | 1.5 | Сүз төркемнәрен кабатлау | 1 | 17.09 | |
| | | **2. СҮЗ (10сәг)** | | | |
| *6* | 2.1 | **Сүз.**Сүзнең туры һәм күчерелмә мәг-се | | 22.09 | |
| *7* | 2.2 | [illegible] | 1 | | |

**4 нче сыйныф укучылары өчен туган тел(татар теле) дәресеннән календарь-тематик план.**

| №п/п | Бүлек № | Дәрес темасы | Сәг саны | Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | план | факт |
| | **1** | **3 сыйныфта үткәннәрне кабатлау (5 сәг)** | | | |
| 1 | 1.1 | Хуш,ямьле җәй! Исәнме, алтын көз! Саумы мәктәбебез! | 1 | 3.09 | |
| 2 | 1.2. | Авазлар һәм хәрефләр | 1 | 7.09 | |
| 3 | 1.3 | Сузык һәм тартык авазлар | 1 | 10.09 | |
| 4 | 1.4 | Татар теленең үзенчәлекле авазлары. Басым | 1 | 14.09 | |
| 5 | 1.5 | Тамыр һәм кушымча.Фонетик анализ ясау | 1 | 17.09 | |
| | **2.** | **Морфология (39 сәг)** | | | |
| 6 | 2.1 | Исем турында төшенчә | 1 | 21.09 | |
| 7 | 2.2 | Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр. | 1 | 24.09 | |
| 8 | 2.3 | Исемнәрнең килеш белән төрләнеше | 1 | 28.09 | |

**I-IV сыйныфларда язма эшләрне бәяләү.**

Хатасыз яки бер тупас булмаган хата хата җибәрелгән; дөрес һәм матур матур язылган эшкә “5”ле куела.

3 тән артык хата булмаса һәм ул пөхтә итеп язылса яки хатасыз, ләкин төзәтүләр белән бик үк пөхтә язылмаган эшкә “4” ле куела.

5 орфографик һәм 1 пунктуацион хаталы эшкә “3” ле куела.

Изложение һәм сочинениеләрне бәяләү

1.Эчтәлек дөрес һәм эзлекле итеп ачылса; җөмләләр грамматик яктан дөрес төзелсә; хаталар булмаса яки 1 орфографик (1 җөмлә төзелешендә) хата җибәрелсә, «5» ле куела.

1 Эчтәлек дөрес ачылып та, эзлеклелек сакланмаса яки пөхтә башкарылып, эзлеклелек булып та, сүз сайлауда һәм җөмлә төзүдә 2—3

хата булса, «4» ле куела.
2 Текстның яки рәсемнең төп эчтәлеге бирелеп тә, эзлеклелек сакланмаса; 4—6 орфографик, пунктуацион хата җибәрелсә; сүзләр кулланганда һәм җөмләләр төзегәндә, 4—5 төгәлсезлек китсә, «3» ле куела.
3 Эчтәлек дөрес һәм эзлекле гчылмаса; 7—10 орфографик, пунктуацион хата җибәрелсә; сүзләр кулланганда, җөмләләр төзегәндә, 6—7 тупас хата китсә, «2» ле куела.

Хаталарны классификацияләү (тупас, тупас булмаган хаталар) милли мәктәпләр өчен эшләнгән нормаларга туры килә.

Язма эшләрдәге сүзләр күләме

| сыйныфлар | сүзлек диктанты | контроль диктант | изложение | сочинение |
|---|---|---|---|---|
| I | 5-7 | 20-26 | - | - |
| II | 7-8 | 28-35 | 45-50 | 40-45 |
| III | 10-12 | 35-45 | 50-55 | 45-50 |
| IV | 12-16 | 45-50 | 60-70 | 50-55 |

Укучыларның телдән сөйләмен бәяләгәндә, аның фонетик, грамматик ягы белән беррәттән сәнгатьлелеге дә исәпкә алына. Телдән сорау формасында үткәрелә торган күнегүләр һәр дәрестә алып барыла.

Тыңлап аңлау күнекмәләрен бәяләү:

1 «тулаем аңлады»;
2 «өлешчә аңлады»;
3 «аңламады».

Укучының монологик сойләмен бәяләү

1. Тәкъдим ителгән тема (рәсем, ситуация) буенча хикәя төзи белсә; дөрес интонация белән, тулы, эзлекле итеп, текстка бәя биреп, мөнәсәбәтен күрсәтеп сөйли алса, тупас булмаган пауза хаталары җибәрелсә дә, «5» ле куела.

1 нче сыйныфта бәйләнешле сөйләм — 6—8,
2 нче сыйныфта — 8—10,
3 нче сыйныфта — 10—12,
4 нче сыйныфта 12—14 җөмлә тәшкил итә.

2. Аерым паузалар, 1—2 сөйләм хатасы ясаса; укытучы тарафыннан икедән артык булмаган ачыклаучы сорау бирелсә, «4» ле куела.

3. Теманың төп эчтәлеген ачса; 4—6 сөйләм хатасы җибәрсә; укытучы тарафыннан икедән артык ачыклаучы сорау бирелсә яки укытучы ярдәменнән башка сөйләмне башлый (тәмамлый) алмаса, «3»ле куела.

4. Сөйләмдә эзлеклелек сакланмаса; паузаларда төгәлсезлекләр китсә; 6 дан артык сөйләм хатасы һәм грамматик хата ясаса, «2» ле куела.

Диалогик сөйләмне бәяләү

1 Тиешле темпта дөрес интонация белән сорау куйса; әңгәмәдәшенең сорауларына тулы җавап кайтарса, «5» ле куела.

2 Дөрес сорау биреп, үзе дә әңгәмәдәшенең соравына дөрес җавап кайтарса, ләкин сөйләм вакытында укытучы ярдәменә мохтаҗ булса; 2—3 сөйләм хатасы җибәрсә, «4» ле куела.

3 Укытучы ярдәмендә генә сорау бирсә яки җавап кайтарса; сораулар биргәндә, сүзләр һәм грамматик формалар табуда төгәлсезлекләр җибәрсә яки өйрәнгән җөмлә калыпларының бер өлешен генә үзләштерсә; 4—5 сөйләм хатасы җибәрсә, «3» ле куела.

4 Әңгәмә вакытында зур авырлык белән генә сорау бирсә; сорауларга үз көче белән җавап бирә алмаса; 6 дан артык хата җибәрсә, «2» ле куела.